РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 4

2020 елның 3 гыйнвары

Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

Э.Р.Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2020 елның 3 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләр

Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге Советының 2013 елның 6 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 3 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 7 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 31-117 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 27-83 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге Советының 2013 елның 6 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге Советының 2013 елның 6 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 статья. Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган төшенчәләр.

Әлеге Кагыйдәләрдә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.»;

2. 4 статьяның 4 пунктындагы 2 абзацында «кабат» сүзен төшереп калдырырга;

3. 4 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентында күрсәтеләләр:

1) җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

2) җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалануны чикләү;

4) территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм әгәр шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру күздә тотыла икән, әлеге объектларның территориаль яктан халык өчен мөмкин булган максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.

Расланган Кагыйдәләр җир кишәрлекләрен һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек объектларын файдалану һәм алар чикләрендә Россия Федерациясе Һава кодексы нигезендә билгеләнгән аэродром яны территориясе тулысынча яисә өлешчә урнашкан аэродром яны территориясендә билгеләнгән икътисадый һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру чикләренә каршы килүче өлештә кулланылмый.»;

4. 5 статьяның 2 пунктында «Башкарма комитет» сүзләреннән соң «Түбән Камамуниципаль районы (алга таба - Башкарма комитет)» сүзләрен өстәргә;

5. 5 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацында «аларны махсус тираж белән бастырып чыгару һәм барлык кызыксынучыларга ачык сату» сүзләрен төшереп калдырырга;

6. 5 статьяның 2 пунктындагы 5 абзацында «Күрсәтелгән хезмәтләр бәясе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә билгеләнә.» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. 2 бүлек исемен түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: «Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир участокларының һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү. Җирле үзидарә органнары тарафыннан территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү.»;

8. 7 статьяның 1 пунктында «(ТР Законнары белән кертелгән үзгәрешләр белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

9. 10 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1. Җирдән файдалану һәм төзелеш буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертүне эшләүне, килештерү һәм фикер алышуны тәэмин итү, җирлек территорияләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру мәсьәләләрен хәл итү буенча тәкъдимнәр карау һәм әзерләү, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләрен хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында төзелә һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы даими эшләүче консультатив орган булып тора (алга таба – Башкарма комитет җитәкчесе).»;

10. 10 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гамәлдәге законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Комиссия:

- гавами тыңлаулар үткәрүне оештыра;

- капиталь төзелеш объектының яисә җир кишәрлегенең шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читләштерүгә рөхсәт бирү мәсьәләләрен карый;

- Башкарма комитет җитәкчесенә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү яки үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне кире кагу турында тәкъдимнәр әзерли;

- әлеге Кагыйдәләрне гамәлгә ашыру һәм куллануга бәйле норматив хокукый актлар, башка документлар проектларын әзерләүне оештыра;

- кирәкле мәгълүматны соратып ала;

- башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

11. 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пунктны өстәргә:

«4. Әлеге кагыйдәләрне аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалану чикләүләре белән тәңгәлләштерүне күздә тоткан Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы проект комиссия тарафыннан каралырга тиеш түгел.»;

12. 2 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 11-12 статьялар белән тулыландырырга:

«11 статья. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү.

1. Капиталь төзелеш объектларының һәм җир участокларының рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү, техник регламентлар таләпләрен үтәү шарты белән, шәһәр төзелеше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре тарафыннан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш, рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм ярдәмче төрләре мөстәкыйль рәвештә өстәмә рөхсәтләр һәм килешүләрсез сайлап алына.

3. Шәһәр төзелеше регламентлары көче аларга кагылмый яисә алар өчен шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләрдә урнашкан капиталь төзелеш объектларының һәм җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү турындагы карарлар федераль законнар нигезендә кабул ителә.

4. Җир кишәрлегенең яки капиталь төзелеш объектының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

12 статья. Җирле үзидарә органнары тарафыннан территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү.

1. Территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү турында карарлар мөстәкыйль рәвештә кабул ителә:

1) төзелгән территорияне үстерү турында шартнамәләр, территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр, шул исәптән стандарт торак төзү максатларында, җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзелгән затлар тарафыннан;

2) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 46.9 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар тарафыннан;

3) аларны реконструкцияләү максатларында территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләгән очракта, реконструкцияләнергә тиеш гамәлдәге линия объектларына ия булучылар тарафыннан (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 12.12 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш);

4) федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү очрагында, табигый монополияләр субъектлары, коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 12.12 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш);

5) бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен әлеге ширкәткә бирелгән җир кишәрлегенә карата бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәт тарафыннан.

2. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракларда, территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү күрсәтелгән затлар тарафыннан аларның акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә җәлеп ителә торган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән затларның территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләүгә чыгымнары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән капланырга тиеш түгел.»;

13. 30 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карау өчен нигез булып тора:

1) мондый генераль планнарга яки муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең җирлекнең генераль планына, муниципаль районның территориаль планлаштыру схемасына туры килмәве;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда үтәү өчен, җирлекнең, җирлекара территориянең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә җибәрелгән аэродром яны территориясендә урнаштырылган күчемсез милек объектларын файдалану чикләүләрен бетерү турында күрсәтмәләр керү;

3) территориаль зоналар чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү;

4) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган шәһәр төзелеше зоналары картасында күрсәтелгән мәдәни мирас объектлары территорияләре, файдалануның аерым шартлары булган территорияләр зоналары чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматның күрсәтелгән зоналар, территорияләр чикләренең урнашу урыннары тасвирламасына туры килмәве;

5) федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар территорияләре, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә тулысынча яки өлешчә урнашкан, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалануның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чикләүләрнең, мондый зоналар, территорияләр чикләрендә күчемсез милек объектларыннан файдалану чикләүләренә туры килмәве;

6) территориядән файдалануның аерым шартлары булган зонаның гамәлдә булуын билгеләү, үзгәртү, туктату, мәдәни мирас объекты, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе, төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен билгеләү, үзгәртү.»;

14. 30 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7. Башкарма комитет җитәкчесе Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул иткәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча, муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, мондый карарны кабул итү турында хәбәрне бастыруны һәм әлеге хәбәрне «Интернет» челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.»;

15. 30 статьяның 7 пунктына «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалану чикләүләренә туры китергән очракта, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында карар кабул итү турында хәбәр бастырып чыгару таләп ителми.» сүзләрен өстәргә;

16. 30 статьяның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8. Башкарма комитет комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең

генераль планына, Түбән Кама муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына, Россия Федерациясенең ике һәм аннан да күбрәк субъектының территориаль планлаштыру схемаларына, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемаларына, Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемаларына, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестры белешмәләренә, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләргә, документларга һәм материалларга туры килү-килмәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

17. 30 статьяның 9, 10 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын Түбән Кама муниципаль районы Башлыгына яисә аның әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә һәм документларга туры килмәве ачыкланган очракта, комиссиягә эшләп бетерү өчен җибәрә.

10) Түбән Кама муниципаль районы башлыгы Башкарма комитеттан Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында проектны алганнан соң, мондый проект алынганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча, мондый проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында, шулай ук, әгәр ул шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларында каралган булса, проектны килештерү өчен җибәрү турында карар кабул итә.»;

18. 30 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар Комиссия тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 28 статьялары, 31 статьясындагы 13,14 өлешләре нигезендә, җирлек уставы һәм (яки) җирлекнең муниципаль хокукый акты белән билгеләнә торган тәртиптә үткәрелә. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалану чикләүләренә туры китергән очракта, җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар үткәрелми»;

19. 30 статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларның яисә гавами тыңлауларның дәвамлылыгы мондый проект басылып чыккан көннән кимендә бер һәм өч айдан да артык вакыт тәшкил итә. Билгеле бер территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү әзерләнгән очракта, Кагыйдәгә үзгәрешләр кертү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар мондый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территориаль зона чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрү вакыты бер айдан да артык була алмый.»;

20. 30 статьяның 13 пунктында «яисә шәһәр округы» сүзләрен төшереп калдырырга;

21. 30 статьяның 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты һәм килештерү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, Комиссия, мондый иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектына үзгәрешләр кертүне тәэмин итә һәм әлеге проектны Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыра. Кагыйдәләр проектына мәҗбүри кушымталар булып, вәкаләтле орган белән (законда билгеләнгән очракларда) килештерү турында бәяләмә, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар беркетмәләре һәм иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә тора.»;

22. 30 статьяның 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Башкарма комитет җитәкчесе, комиссия бәяләмәсендә булган тәкъдимнәрне исәпкә алып, утыз көн эчендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында яки әлеге кагыйдәләргә үзгәреш кертү турында тәкъдимне кире кагу турында, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, карар кабул итә һәм мондый карарның күчермәсен мөрәҗәгать итүчеләргә җибәрә.;»;

23. 16,17 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр керткәндә. Түбән Кама муниципаль районы Советы каравына тәкъдим ителә:

- нигезләү документлары белән үзгәрешләр кертү турында Комиссия тарафыннан әзерләнгән карар проекты;

- шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Башкарма комитетның структур бүлекчәләре белән үзгәрешләрне килештерү;

- Комиссия бәяләмәсе;

- вәкаләтле орган бәяләмәсе, әгәр мондый килешүне алу шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында каралган булса;

- авами тыңлаулар беркетмәләре һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.

17. Түбән Кама муниципаль районы Советы, Кагыйдәләргә үзгәрешләр һәм мәҗбүри кушымталарга үзгәрешләр кертү проектын карау нәтиҗәләре буенча, кертелә торган үзгәрешләрне расларга яки әлеге проект буенча иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәгә туры китереп, Башкарма комитет җитәкчесенә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын эшләп бетерү өчен җибәрергә мөмкин.»;

24. 30 статьяның 20 пунктында «Россия Федерациясен территорияне планлаштыру схемалары» сүзләреннән соң «Россия Федерациясенең ике һәм аннан да күбрәк субъектларының территорияне планлаштыру схемаларына» сүзләрен өстәргә;

25. 35 статьяның «Шәһәр төзелеше регламентлары. Рекреацион файдалану зоналары» бүлегенең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рекреацион билгеләнештәге зоналар составына шәһәр урманнары, скверлар, парклар, шәһәр бакчалары, буалар, күлләр, сусаклагычлар, пляжлар, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары урнашкан территория чикләрендәге, шулай ук ял итү, туризм, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен файдаланыла торган башка территорияләр чикләрендәге зоналар кертелергә мөмкин.»;

26. 2 статьяның 2, 3 пунктларында, 30 статьяның 10, 13,15-16 пунктларында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «иҗтимагый тыңлаулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

27. 5 статьяның 5 пунктында, 30 статьяның 13 пунктында «гавами тыңлауларда» сүзләрен «иҗтимагый фикер алышуларда яисә гавами тыңлауларда» сүзләренә алмаштырырга;

28. 2 статьяның 3 пункты, 3 статьяның 5 пункты, 7 статьяның 3 пункты, 8, 9 статьялар, 3-7 бүлекләр, 32 статьяның 2-6 пунктлары, 36 статьяның 3-6 абзацлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина